ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

26 март 2026 ел Новотроицк авылы № 2

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Күперле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2025 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Күперле авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Күперле авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Күперле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2025 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Күперле авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2026 елның 8 апрелендә 17.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1)түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Күперле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

-җир асты суларының (чишмәнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү;

-Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәле территориясен сатып алу һәм койма белән тәэмин итү)»;

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Күперле авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын урнаштыру).

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2025 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Күперле авылында гражданнар җыены карарының 1 пунктында икенче-өченче-дүртенче абзацында:

-җир асты суларының (чишмәнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү;

-Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәле территориясен сатып алу һәм койма белән тәэмин итү)»;

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Күперле авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын урнаштыру).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күперле авылы, Зур урам, мәчет янында.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева